РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«19» февраль 2026 г. г. Альметьевск № 19

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 150 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 31, 32 бүлекләре нигезендә, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 29 статьясына таянып

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 150 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2015 елның 6 маендагы 178, 2015 елның 23 октябрендәге 11, 2018 елның 17 июлендәге 124, 2018 елның 15 ноябрендәге 127, 2021 елның 28 сентябрендәге 45 , 2024 елның 13 ноябрендәге 155 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4.1 пунктчасы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артык булган салым салу объектлары, проект буенча күпфатирлы йорт булып торучы төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»;

1.2. 3 пунктның 3.1, 3.2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затлар (мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);

3.2. балигъ булмаган балалар һәм белем бирү оешмаларында көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар, шулай ук әлеге пунктның 3.1 пунктчасында күрсәтелгән физик затлар;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Семенихин А.В.).

Шәһәр башлыгы Г.М. Хәбутдинова